ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 11-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 11-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 9 октябре
№ 83-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелә

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы ундүртенче абзацына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 95 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«ландшафт (табигый) янгыннарын (урман фонды җирләрендә, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарыннан тыш) сүндерү планнарын эшләү һәм раслау, шулай ук мондый янгыннарны сүндерүне Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар нигезендә эшләүче гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чаралары белән оештыру;».

**2 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) беренче өлешгә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү чараларын үткәрү, гадәттән тыш хәлләрдә кешеләрне үлемнән коткаруга һәм аларның сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру.»;

б) икенче өлештә «егерме өченче» сүзләреннән соң «, егерме алтынчы» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 26 ноябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – ТР законы проекты) Татарстан Республикасы норматив хокукый базасын федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә үстерү максатларында эшләнде.

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законга һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 16 һәм 18 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 маендагы 125-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына ландшафт (табигый) янгыннарын (урман янгыннарыннан тыш) сүндерү планнарын эшләү һәм раслау, шулай ук гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү чараларын үткәрү вәкаләтләре бирелде.

Федераль законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, ТР законы проекты белән «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертү күздә тотыла.

ТР законы проекты өч статьядан тора. 3 статьяда Татарстан Республикасы Законының үз көченә керү вакыты 2024 елның 26 ноябреннән башлана дип карала.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү законнарның үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башка законнар кабул итүне таләп итми.

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгы тарафыннан ландшафт (табигый) янгыннарын (урман фонды җирләрендә, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарыннан тыш) сүндерү планнарын эшләү һәм раслау тәртибе расланганнан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан әлеге планнарны раслауны таләп итәчәк.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.